ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 81

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«16» май, 2022 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2021 елның 21 декабрендәге 205 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актның аерым нигезләмәләренә төзәтмәләр кертү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2021 елның 21 декабрендәге 205 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет составына кимендә 5 һәм иң күбе 9 кеше керергә тиеш.»;

5.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер мәртәбәдән дә ким булмаган күләмдә үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар, утырыш уздырганнан соң ун календарь көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә.»;

6.6 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә.».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны җитәкче урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С.Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов